РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080
тел.: (84360) 2-11-89 (факс),
E-mail: Telache@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ**

422080, Теләче авылы, Ленин урамы, 46,
тел.: (84360) 2-11-89 (факс)
E-mail: Telache@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 47** **«13» август 2010 ел**

## «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең квалификациясен һәм стажировкасын арттыру турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Теләче муниципаль районы Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында Нигезләмәне (1 номерлы кушымта) расларга.
2. «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказны урнаштыру өчен вәкаләтле зат итеп Теләче муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.
3. Авыл җирлекләре башлыкларына 2010 елның 15 августына кадәр үз территорияләрендә муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында шундый ук нигезләмәләр әзерләүне һәм раслауны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Башлыгы аппараты җитәкчесе Р.В. Нигъмәтҗановка йөкләргә.

И. М. Низамов

1 номерлы кушымта
Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы
Башлыгының 2010 елның «13»
августындагы 47 номерлы
карары белән расланган

НИГЕЗЛӘМӘ

«Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм башка федераль законнар, Татарстан Республикасының башка законнары, Теләче муниципаль районы Уставы, Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә, башка норматив хокукый актлар нигезендә эшләнде һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ (алга таба - муниципаль заказ) формалаштыру тәртибен билгели.

2. Муниципаль район Башкарма комитетының кадрлар мәсьәләләре буенча оештыру бүлеге (алга таба - оештыру бүлеге) белгече җирле үзидарә органнары гаризалары нигезендә,муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри белемен яңартуга, квалификацияләрен күтәрүгә һәм стажировкага ихтыяҗ нигезендә төзелгән, муниципаль заказ структурасын билгели һәм аны финанслау күләмен күздә тота.

3. Муниципаль заказда түбәндәге белешмәләр бар:

- укырга тиешле муниципаль хезмәткәрләрне саны (һөнәри яңадан әзерләү, квалификация күтәрү һәм стажировка программалары буенча аерым);

- уку өчен түләү өчен кирәкле чаралар күләме (һөнәри яңадан әзерлек программалары буенча аерым, стажировка квалификациясен күтәрү).

4. Муниципаль заказ түбәндәге нигездә оештыру бүлеге тарафыннан исәпләнә:

- муниципаль хезмәт вазыйфалары категорияләре һәм төркемнәре, юнәлешләре, төрләре, рәвешләре һәм укыту сроклары буенча бүленергә тиешле муниципаль хезмәткәрләрнең фаразлана торган саны;

- муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри белемен яңарту, квалификациясен һәм стажировкасы буенча белем бирү хезмәтләре бәясенең икътисадый нормативлары.

Муниципаль заказ календарь елга, 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр (алга таба - хисап елы) исәпләнә.

Кадрларны муниципаль заказга өйрәтү ихтыяҗын исәпкә алганда түбәндәгеләр керми:

- хисап елында муниципаль хезмәтне туктатуны күздә тоткан муниципаль хезмәткәрләр;

- муниципаль хезмәттән аерылмыйча, югары уку йортларында, аспирантурада белем алучы муниципаль хезмәткәрләр;

- исәп-хисап елында озакка сузылган отпускларда (йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, бала карау ялы) һәм озак вакытлы хезмәт командировкаларында булган муниципаль хезмәткәрләр.

Укырга тәкъдим ителүчеләр составына вазыйфаи күчешләргә кандидатлар булган муниципаль хезмәткәрләр (югарырак вазыйфа яисә башка профиль вазыйфасын биләү) һәм муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кабул ителгән затлар кертелә.

Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри белемен яңарту, квалификацияләрен күтәрү һәм стажировкалау кирәк булган саен, кимендә биш елга бер мәртәбә уздырыла.

5. Муниципаль заказ түбәндәге тәртиптә төзелә:

- җирле үзидарә органнары планлаштырыла торган елның 1 сентябренә кадәр муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри белемен яңартуга, квалификацияләрен һәм стажировкасын арттыруга гаризаны килештерү өчен оештыру бүлегенә тапшыра (1 номерлы кушымта);

- планлаштырыла торган елга кадәрге елның 15 сентябренә кадәр, җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән гаризалар нигезендә, оештыру бүлеге муниципаль хезмәткәрләрне укытуга ихтыяҗны үткәрелгән анализы нигезендә муниципаль заказ проектын 2 номерлы кушымта нигезендә әзерли;

- чираттагы финанс елына җирле бюджет проектын формалаштыру өчен Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары билгеләгән срокларда, оештыру бүлеге чираттагы финанс елына Теләче муниципаль районы бюджеты проектына кертү өчен Теләче муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль заказ проектын җибәрә;

- Теләче муниципаль районы бюджеты турында карар үз көченә кергәннән соң, оештыру эше бүлеге муниципаль заказ күләмен төгәлләштерә һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгына раслауга проект тәкъдим итә.

6. Муниципаль заказ «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы тарафыннан раслана.

7. Муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри яңадан әзерләүгә һәм квалификацияләрен күтәрүгә лицензиясе булган һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә муниципаль заказ урнаштыру һәм дәүләт аккредитациясе «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар күргәзмәсенә заказлар урнаштыру, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

1 номерлы кушымта
«Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында Нигезләмәгә

муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга гариза ____ ел

______________________________________________________________

(башкарма хакимият органы исеме)

| № | муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.И. | Вазифа атамасы | Муниципаль хезмәт стажы | ДПО юллама бирү (муниципаль хезмәткә кабул итү, вазыйфага билгеләү, кадрлар резервына кертү, аттестация үткәрү һ.б.) | Өстәмә һөнәри белем бирү төре (белемнәрне яңарту, квалификация күтәрү, стажировка) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Муниципаль берәмлек Башлыгы ____________________ ________________
(имза) (Ф.И.А.И.)

« » _____20_____ел
(дата)

2 номерлы кушымта «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ турында Нигезләмәгә

# Һөнәри белемнәрен яңартуга, квалификациясен күтәрүгә һәм стажировкасын арттыруга муниципаль заказ _______ ел

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары төркеме исеме | Укуга җибәрелә торган муниципаль хезмәткәрләр саны (кеше) | | | | Бүлеп бирелә торган бюджет акчаларының гомуми суммасы (мең сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | шул исәптән мәгариф программалары буенча | | | барлыгы | шул исәптән | | |
| | | һөнәри әзерлек | квалификация күтәрү | стажировка | | һөнәри әзерлек | Квалификация күтәрү | стажировка |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

Муниципаль берәмлек башлыгы __________________ ______________________
(имзасы) (Ф.И.А.И.)

«___» ______________ 20___ел
(дата)